күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

Энче чыгарылыш

5 нче декабрь

## Мәктәп яңалыклары...

Мәктәп, мәктәп! Һәркемнең күңелендә мәктәп еллары мавыктыргыч, күңелле булып, кызыклы вакыйгалары белән истә кала.

Мәктәп ул –укучының икенче йорты. Монда ул белем ала, күп нәрсәләргә өйрәнә, мәктәп тормышында “кайный - кайный” зур тәҗрибә туплый...

Мәктәбебездә төрле чаралар, бәйрәм, кичәләр гел үткәрелеп тора. Зур әзерлек белән оештырылган бу чаралардан укучылар шатланып кайтып китәләр. Укучылар тарафыннан әзерләнгән флеш-моб әнә ничек кызык үтте!

Ә нәтиҗәләре түбәндәгечә булды:

Гран-при-6 “А”

5-6 сыйныфлар арасында

1 урын-6“В”

2 урын-5“А”,5“В”

3 урын-5“Д”,5“Е”

4 урын-5“Б”

7-9 сыйныфлар арасында:

1 урын-9“А”, 8“Г”

2 урын-8“А”

3 урын-9“Б”

Укучылар, афәрин!

Мәхмүтова Мәликә, “Күкнең җиденче катында” гәҗите әгъзасы







БУ САНДА:

Мәктәп яңалыклары 1

«Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! 2

Инша яздым, утырып... 3

Көтеләчәк бәйгеләр. Котлыйбыз! 4

## Истәлек битләре буйлап...


Фатих Кәрим – шагыйрь, көрәшче һәм патриот. Әдәбиятка килгән елларыннан ук үзенең зәвыклы, тырыш иҗатчы булуын күрсәтә. Аның Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Кави Нәҗми кебек якын дуслары Фатих Кәримнең хезмәт сөючән, эшлекле, пөхтә, үз-үзенә дә, иптәшләренә дә игътибарлы, таләпчән, олы җанлы кеше булуы турында язалар …

21 нче ноябрь көнне мәктәбебездә Фатих Кәримнең кызы Ләйлә Фатыйхова белән очрашу кичәсе узды. 8Б,В, Г сыйныфы укучылары белән җанлы әңгәмә узды.Ләйлә Фатыйхова ,әнисе истәлекләреннән чыгып, әтисе турында сөйләде.

Укучылар шагыйрьнең катлаулы тормышы белән танышып, күңелләре аша кичереп утырдылар. Кичәдән алар бик канәгать калдылар.







# «Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!»

20 нче ноябрь көнне ,“Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!”исеме астында, район күләмендә шигырь сөючеләр бәйгесе оештырылды. Бәйге искиткеч күңелле узды.Шигырь сөюче нәни “йолдызчыклар” матур, эчтәлекле шигырьләрен сөйләделәр. Әниләренә багышлап үзләре дә шигырь чыгарганнар иде,хәтта. Мәгъсумова Мәрьямның (2 “Г” сыйныфы, укытучысы:Насыйбуллина А.И.) үзе чыгарып, әнисенә юллаган эчтәлекле шигыре генә ни тора?! Юкка гына 1нче урынны яулагандыр ул?!



Әнием! Әнием! Әнием!

Таң нурыдай назлы кулларың.

Әнием тик сиңа багышлап,

Җырлыйлар яраткан кызларың.

Безнең мәктәбебездә “Әниләр бәйрәме” аеруча матур булды. Бар сыйныф бәйрәмгә тырышып әзерләнде. Әниләребезгә иң изге теләкләр яңгырады, шигырьләр сөйләнеп, җыр – биюләр багышланды. Никадәр ихласлылык җылытты ул кичәне: күңелдән нур булып ярып чыккан котлау сүзләре, шатлыктан күз читләрен чылаткан кайнар яшьләр, тыеп калып булмый торган хисләр ташкыны... Җырларның һәр нотасы да, биюләрнең иң гади хәрәкәтләре дә, шигырьләрнең һәр рифмасы да, һәрберебезнең үз әнисенә карап алган күз карашы да – барысы да күңел түренә үтеп кереп онытылмаслык хатирәгә әверелде

Алукаева Зәринә,5 “Е” сыйныфы








# Күңел җылысыннан чыккан шигырьләр...

**Әнием**

Минем әнием бик уңган,
Тәмле ашлар пешерә.
Без укудан кайту белән,
Дәрес карарга булыша.
Шундый булган әни безнең,
Аны хөрмәт итәбез.
Бәйрәм саен яратып,
Чәчәк бүләк итәбез.

Мәгъсумова Мәрьям, 2 «Г» сыйныфы

**Әнием**

Әниләрнең кадерен белик,
Алар безне үстерә.
Яхшылыкка өйрәтеп,
Тормыш юлын күрсәтә.
Әниемне мин яратам,
Аның куллары алтын.
Бәхет, шатлыклар телимен,
Ул безгә бик тә якын

Сәлихҗанов Салават, 4 “А “сыйныфы

**Җан биргән кеше бит син !**

Әни – иң газиз, якын кеше син,
Кадер-хөрмәт иясе.
Чиксез рәхмәтем белдереп,
Килә башым иясе.
Бу дөньяга китергән,
Җан биргән кеше бит син!
Иркәләп, назлап уяткан,
Ягымлы кешем дә син!

Мәхмүтова Мәдинә, 5 “Е” сыйныфы

# Инша яздым утырып...

"Күкнең җиденче катында" түгәрәгенә йөрүче укучыларыбыз берсеннән-берсе матур шигырьләр, иншалар иҗат итә. Түгәрәккә әле яңа гына каләм тибрәтә башлаучы укучылар да йөри.

Каләм тибрәтүчеләребезгә алга таба да иҗат уңышлары телибез, илһам чишмәләре беркайчан да саекмасын!

Әни... Нинди олы, мәгънәле сүз бу!
Минем әнием иң матур әни . Мин аны бик, бик яратам . Аның исеме - Лилия . Әни китаплар укырга ярата . Элек ул шигырьләр дә яза иде .

Әни игелекле һәм ягымлы . Ул безнең өчен үрнәк . Мин аңа ошарга телим. Аның кебек хуҗабикә буласым килә .

Ул үз өстендә дә күп эшли, француз телен дә өйрәнде, хәтта .

Менә нинди уңган, булган, тырыш ул!
Фәтхуллина Адилә ,5 "Е" сыйныфы

Минем әниемнең исеме җисеменә туры килә-Гүзәл.Аңа утыз җиде яшь.Бакый Урманче исемендәге икенче татар гимназиясендә укыган.Гимназиянең тормышында да бик актив катнашкан.Төрле концертлар алып барган,шәһәрдә узган чараларда катнашкан, бәйгеләрдә җиңү яулаган.Укуда да алдынгы укучылар рәтендә булган.Мәктәптән соң Казан Дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлаган.Казанда да төрле чаралар алып баручы,режиссер булып эшләгән.Хәзер ул үзебезнең киностудиябезне җитәкли һәм татарча гәҗитнең баш мөхәррире булып эшли.Шулай ук күп милләтле якшәмбе мәктәбендә методист булырга да өлгерә.Ә өйдә ул безнең яраткан әниебез һәм менә дигән пешекче!Мин үземнең әниемне яратам һәм хөрмәт итәм.
Мәхмүтова Мәдинә ,5 "Е" сыйныфы.

Минем әниемнең исеме-Ландыш.Аңа 36 яшь.Ул балалар бакчасында татар теле укыта.Балаларны ярата, алар белән төрле уеннар уйный.Алар да аны ярата.

Минем әнием дөньядагы иң матур кее.Аның күзләре зәңгәр , чәчләре - сары .

Әнием оста пешекче дә. Дөньяда аның пешергән ризыгыннан да тәмле әйбер юктыр!

Әнием һәр кешегә кулыннан килгәнчә булышырга тырыша.

Мин әниемне яратам, чөнки аннан да кадерлерәк кеше юк!

Эльза Гаврилова, 5 "Е" сыйныфы

****************************

Бүген мин яраткан әнием турында язам...

Минем әниемнең исеме- Әлфия.Әни бухгалтер булып эшли.Буш вакытта әни телевизор карый.Ул бик тәмле пешерә һәм ял көнне безне пицца белән сыйлый. Минем әнием акыллы, матур, игелекле.Әни дәресләр ясарга үгетли.Ял көннәрендә паркта йөрибез.Мине әнием төрле түгәрәкләргә йөртә.Әнием машинаны йөртә белә.Без әни белән бик дус.Мин әниемне бик яратам.

Хәйриев Самат,5"Д" сыйныфы укучысы

Минем әни иң яхшысы. Аның исеме -Лилия.

Аңа 38 яшь.Ул 1980 елның15 ноябрендә туган.Аның ике кызы бар.Бу -мин һәм минем сеңелем.Минем әни бик матур акыллы ,ярдәмчел.Теләсә нинди вакытта минем әни миңа ярдәм итәчәк.

Үз әниеңне хөрмәт итәргә һәм яратырга кирәк! Чөнки алар безне дөньяга китерделәр.Әгәр алар булмаса,без дә булмас идек.

Алукаева Зәринә , 5 "Е" сыйныфы

**************************************

Минем әниемнең исеме- Гүзәл.

Гүзәл исеме "матур" дигәнне аңлата.Минем әниемә утыз җиде яшь.Ул беренче августта туган.Түбән Кама шәһәренең Бакый Урманче урамында яшәгән.Шулай ук Бакый Урманче исемендәге икенче татар гимназиясен тәмамлаган.Төрле түгәрәкләргә йөргән,кечкенәдән зур сәхнәдә чыгыш ясаган.Шәһәр чыршы бәйрәмнәрен,Сабан туйларын, "Нәүрүз"ләрен дә алып барган.

Казанның мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлагач та зур сәхнәләрдә төрле чаралар алып барган.

Минем әнием бик эшчән һәм тырыш.Ул хәзер дә төрле чараларда катнаша. Әниебез безгә дә вакыт таба, безнең белән ял паркларына чыга, безне әбибабай янына кунакка да алып кайта. Без аны бик яратабыз

Мәхмүтова Мәликә , 5 "Е" сыйныфы

**************************************

Минем әниемнең исеме -Гөлнара.Минем әниемә утыз өч яшь.Ул хусапчы булып эшли.Минем әнием бик матур ,гүзәл,яхшы һәм акыллы .Ул мина дәрес әзерләргә булыша.Мин мәктәптән кайтканда ,ул мине тәмле ашлар,итләр белән сыйлый.Авырганда безне дәвалый һәм файдалы ашлар ашата.Безнең әниебез иң яхшы.

Вәлиева Диләрә, 5 "Е" сыйныфы

Әнием иң акыллы, тырыш, гүзәл, чибәр һәм киң күңелле кеше.Һәр көнне әни иртән торып иртәнге чәй әзерли,безгә назлап эндәшеп уята, үбеп озата.

Әни һәркөнне эшкә йөри. Эштә әнине бик хөрмәт итәләр һәм яраталар.Өйгә кайткач та әни эшли, бер дә тик тормый. Мин аңа булышам:чәчәкләргә су сибәм, идәннәрне юам, тузан сөртәм. Мин әнигә ашарга пешерергә дә булышам.Без тиз генә тәмле ашлар пешереп куябыз да,әни белән төрле букчалар,бизәнү өчен бизәнгеч савытлары ясыйбыз.

Без китап укырга яратабыз.Әмма әниемнең китап укырга вакыты аз, шуңа күрә без аудиокитаплар тыңлыйбыз.

Минем уемча, әнисез миңа бик авыр булыр иде.Мин әнидән үрнәк алам! Аның кебек булырга хыялланам.

Мельникова Аделина 5»Д.» сыйныфы

күп профильле
181 нче мәктәп

Тулпар урамы, 2нче йорт

Телефон: 89050229576

Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru

Безнең девизыбыз:

«Без-өлгерләр!»

Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Михайлова Гөлнара Миннегали кызы

Кашапов Наил Нургали улы

Курочкина Аделина Айрат кызы

Сабиржанов Алмаз Ревал улы

Балантаева Людмила Владимировна

Сезне туган конегез белән ихлас котлыйбыз.Бәхетле, озын гомер телибез!

Озын гомер, ак бәхетләр

Сезгә бездән теләкләр.

Шушы кызыл розалар,

Булсын Сезгә бүләккә!



# Планлаштырылган бәйгеләр...

**Кадерле укучылар!**

Сезне игътибарга булачак бәйгеләрнең, ярышларның кайберләрен яктыртып үтәбез.

1. “Кызыл лента, без—яшәү өчен!” акциясе (1.12)

2) “Ягымлы кар бөртеге” теләкләр акциясе (4.12-10.12)


3) “Капка төбендә - Яна ел” (11.12)

4) “Яна ел уенчыгы” бәйгесе

5)”Әкияти Яна ел” , рәсем кургәзмәсе (5.12)

6)”Синен караш”, фото- сурәт (6.12)

7) “Башмаклар һәм башлыклар” коне (26.12)



Редколлегия:
Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина
Житәкчесе:А.Ф.Габдуллажанова